Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN
УНИВЕРСИТЕТ

12+

№2 (53)
24 гыйнвар 2013 ел

## • Универ хәлләре

22 ГЫЙНВАР КӨННЕ КФУ ректоры Илшат Гафуров җитәкчелегендә **РЕКТОРАТНЫҢ ЧИРАТТАГЫ УТЫРЫШЫ БУЛДЫ**. Җыелышта фундаменталь фәннәр буенча хезмәтләре өчен КФУ хезмәткәрләренә стипендия булдыру, яңа кабул итү кампаниясенә әзерлек, дөньядагы иң алдынгы югары уку йортлары белән хезмәттәшлек турында сөйләшү булды.

Төп мәсьәләләргә күчкәнче, Илшат Гафуров Массакүләм коммуникацияләр һәм социаль фәннәр институты директоры **НАИЛ МӨХӘРРӘМОВНЫ ЮБИЛЕЕ БЕЛӘН ТӘБРИКЛӘДЕ**. «Сезнең тәҗрибәгез дә, алда торган мәсьәләләрне дә тормышка ашырырга теләгегез дә, вакытыгыз да җитәрлек», – диде ул котлау сүзләренә кушып.

Ректор һәр фәнни хезмәткәрдән дәрәҗәле журналларда чыккан фәнни мәкаләләрен КФУ сайтына куеп баруын сорады.

Гадәттәгечә, Административ эшләр буенча проректор – КФУ аппараты җитәкчесе **АНДРЕЙ ХАШОВ** контроль күрсәтмәләрнең үтәлеше белән таныштырды.

КФУның Фәнни эшчәнлек буенча проректоры **ДАНИС НУРГАЛИЕВ** фундаменталь фәннәр өлкәсендә куелган хезмәтләр өчен бирeләчәк стипендиянең нигезләмәсенә аңлатма бирде. Аның буенча, стипендия иң нәтиҗәле, актив фәнни һәм фәнни-педагогик хезмәткәрләргә бирeләчәк. Мәкаләләр басылырга гына түгел, ә аларга сылтамалар саны да күп булырга тиеш. Стипендия ике төрле булачак. Берсе утыз алты яше тулмаганнарга, икенчесе өлкәннәргә бирeләчәк. Нигезләмә белән килешмәүчеләр юк иде. Киләсе утырышларда рәсми рәвештә расланыр дип көтелә.

Кабул итү комиссиясенең җаваплы сәркатибе **СЕРГЕЙ ИОНЕНКО** 2013 елгы кабул итү кампаниясенә әзерлекнең барышы турында сөйләде. Статистика буенча, Казан университеты студенты булырга теләүчеләр шактый икән. Бу уңайдан, 17 февраль көнне КФУ «ачык ишекләр» көне уткәрәчәк.

• • • •

20 ГЫЙНВАРДА КФУның Балалар университетында **«ЕВРОПА БЕРЛЕГЕНЕҢ ӘКИЯТИ ИЛЕ»** конкурсының **КАТНАШУЧЫЛАРЫН ҺӘМ ҖИҢҮЧЕЛӘРЕН ТӘБРИКЛӘҮ ТАНТАНАСЫ БУЛДЫ**. Бирегә килгән һәр бала Россиядә Европа Берлегенең Вәкиле һәм ЕС VOICES үзәгенең ЕС символикалы бүләкләрен тәэп кайтып китте.

• • • •

21 ГЫЙНВАР КӨННЕ «Сәламәтлек – 2013» ТР югары уку йортлары хезмәткәрләре һәм профессор-укытучылары составының спартакиадасы башланып китте. Программада 8 спорт төре каралган. Казан федераль университеты беренче уңышлары белән мактана да ала. Доцент Политова С.П., Гаврилов В.Н. һәм өлкән укытучы Гусенков А.М. составында шахмат буенча җыелма команда бронза медаль яулады.

• • • •

Шул ук көнне Казан Кремлендә 26 декабрь көнне 80 яше тулган Россия Фәннәр академиясе һәм ТР Фәннәр академиясе академигы, Мэрилин Университеты (АКШ) физика профессоры **РОАЛЬД СӘГЪДИЕВНЫ** ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов «Татарстан Республикасы алдындагы хезмәтләре өчен» ордены белән бүләкләде.

• • • •

Һиндстан хөкүмәте **КАЗАН ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫНА 10000 ДОЛЛАР КҮЛӘМЕНДӘ ФИНАНС ГРАНТЫ БҮЛЕП БИРГӘН**. Бу безнең университетның Һиндстан-Россия академия мобильлеге өлкәсенә керткән зур өлеше белән аңлатыла.

• • • •

Казан университеты нәшриятында ТР Фәннәр академиясе корреспонденты, профессор А.М.Шелкунов редакциясендә **«ТЕРРОРИЗМ ҺӘМ ЭКСТРЕМИЗМ ПРОФИЛАКТИКАСЫ»** исемле фәнни-методик җыентык (Казань: Казанский университет, 2012. - 108 с.) **ДӨНЬЯ КҮРДЕ**.

• • • •

18 ГЫЙНВАР КӨННЕ университетның Көнчыгышны өйрәнү һәм халыкара мөнәсәбәтләр институтында **ТӨРКИЯНЕ ӨЙРӘНҮ ҮЗӘГЕ АЧЫЛДЫ**. Юныс Эмре исемендәге әлеге фәнни-тикшеренү үзәге Төркиянең сәяси, иҗтимагый, икътисади һәм милли тормышын өйрәнү белән шөгыльләнәчәк.

*kpfu.ru сайты материаллары файдаланылды.*



*Фотода – 1- ректор И.Гафуров В.Рубцовка рәхмәт хаты тапшыра. 2 - Яңа җитәкче - О.Северьянов.*

Алия Гәлимуллина, Руслан Гыйниятов фотосы

Илшат Гафуров:

# «Хезмәт хаклары артачак»!

**Динара МИННЕКАЕВА,**
хәбәрче

23 гыйнвар көнне Казан федераль университетының икенче чираттан тыш профсоюз конференциясе узды. Анда КФУ ректоры Илшат Гафуров, укуукыту эшләре буенча проректор Рияз Минзарипов, административ эшләр буенча проректор – аппарат җитәкчесе Андрей Хашов катнашты.

Конференциянең максаты - сигез ел дәвамында профсоюз белән җитәкчелек иткән Владимир Рубцовның эштән китүе һәм яңа җитәкче сайлау иде. Утырышның эш тәртибе, президиум билгеләнгәч, беренче булып сүз Владимир Рубцовка бирелде. «Бу урында утырырга тиешле вакыт үткәндер дип уйлыйм. Мин җитәкчелек иткән чорда бик күп үзгәрешләр кичерергә, тискәре сүзләр ишетергә, шулай да эшне югары дәрәҗәдә башкарырга туры килде. Казан федераль университетына биш мәртәбәкыйль югары уку йорты кушылу да эзсез калмады, ләкин без бик акыллы рәвештә уртак фикергә килдек. Ныклы фундамент бар, бу урынга җаваплы кешене куярга кирәк. Эш чынлап та авыр, аны алып барыр өчен зур көч сорала», – диде.

Профсоюзда шундый традиция дә бар икән: җитәкче ике сроктан артык эшләми. Югары уку йортлары берләшкәч, профсоюз үз эшчәнлеген тагын да көчәйтеп җибәрә. Бөтен көчле якларны туплап, яңа килешү барлыкка килгән. Әйтергә кирәк, оешма башкарган эшләр нәтиҗәле. Мисалга социаль ипотеканы китерергә мөмкин. 2010 елда башланган программа буенча 2011 елда 56 кеше фатирлы булса, 2012 елда бу күрсәткеч 86га җиткән. Әлбәттә, монда университет администрациясенең дә ярдәме зур. «Без бөтен проблемаларны да өстәл артында хәл иттек. Урамга чыгып, кычкырып йөрмәдек. Безнең хәлгә һәрвакыт керделәр. Барсы өчен дә зур рәхмәт», – диде Владимир әфәнде чыгышын йомгаклап.

Яңа урынга алты кандидат тәкъдим ителде. Аларның һәркайсы да университет үсешенә үз өлешен керткән шәхесләр. Кандидатларның берсе җитәкче буларак билгеләнә, калганнары резервта кала. Идарә итү һәм территориаль үсеш институты доценты Олег Иван улы Северьянов профсоюз җитәкчесе итеп бертавыштан сайланды. Яңа җитәкче Казан дәүләт университетының тарих факультетын тәмамлаган. Армия сафларында хезмәт итеп кайткач, ул аспирантурага керә һәм 1992 елдан укыта башлый. Бу көнгә кадәр ул профсоюзның тормышкөнкүреш комиссиясе рәисе булып тора.

Профсоюзның эшчәнлеген ректор Илшат Гафуров та югары бәяләде. «Бер проблеманы хәл итсәң, аның икенчесе килеп чыга. Авырлыклар алдында туктарга ярамый. Бу көнгә кадәр бер мәсьәлә дә хәл ителмичә калмады. Хезмәткәрләрне торакль итү буенча да шактый эшләр башкарылды. Махсус йорт төзелә башлады, тулай торакларны да фатир рәвешендә үзгәртү күздә тотыла.

## • Бездә кунак бар

# Төркиягә якынаябыз

**Зилә ФӘСХИЕВА,**
хәбәрче

22 нче гыйнвар көнне КФУның филология һәм сәнгать институтында Төркия Республикасының Казандагы генераль консулы Сабри Тунч Ангылы белән эшлекле киңәшмә булып үтте. Очрашуда институт директоры Рәдиф Җамалетдинов һәм ФСИ галимнәре катнашты.

Киңәшмә барышында Сабри Тунч Ангылы *(рәсемдә)* Төркиядә русча камил сөйләшә белүче белгечләргә ихтыяҗ зур булуына басым ясады. Аның сүзләренә караганда, рус оешмалары Төркия Республикасында шактый киң үсеш алган. Бу өлкәдә КФУ белән хезмәттәшлек итү уңышлы нәтиҗәләр бирәчәк. Бүгенге көндә Филология һәм сәнгать институтында барлыгы 209 чит ил студенты белем ала, шул исәптән Төркиядән дә укучылар бар. 2012 елда рус филологиясенә барлыгы сигез төрек студенты укырга килгән. Хәзер алар барлыгы - 14. Мөгаллимнәр исә Төркия студентларының максатчан һәм бик тә ярдәмчел булуын билгеләп үтте.

**Ахыры 2нче биттә.**



Рамил Гәлизов фотосы

• Үткәнгә – нәтиҗә, киләчәккә – планнар!

# Рәдиф Җамалетдинов: «Ният-максатларыбыз зурдан!»

**Динара МИННЕКАЕВА,**
хәбәрче

2013 ЕЛНЫҢ БЕРЕНЧЕ АЕ ТӨГӘЛЛӘНЕП КИЛӘ. КЕМДЕР ӘЛЕ УЗГАН ЕЛ МӨШӘКАТЬЛӘРЕН ХӘЛ ИТӘ, Ә КЕМНӘРДЕР ИНДЕ КИЛӘЧӘККӘ ЯҢА ПЛАННАР, ЗУР МАКСАТЛАР КОРА. УКУ ЙОРТЫБЫЗДА ДА ЭШ КАЙНЫЙ. ИНСТИТУТЛАРДА НИНДИ ЯҢАЛЫКЛАР БАР ИКӘН? ҮЗЕБЕЗНЕ КЫЗЫКСЫНДЫРГАН СОРАУЛАРГА ҖАВАПНЫ ДИРЕКТОРЛАР БЕЛӘН БЕРГӘЛӘП ЭЗЛИБЕЗ. БЕРЕНЧЕ БУЛЫП, ЮГАРЫ УҢЫШЛАРГА ИРЕШКӘН ИҢ ЗУР ИНСТИТУТЛАРНЫҢ БЕРСЕ - ФИЛОЛОГИЯ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ ДИРЕКТОРЫ, ПРОФЕССОР РӘДИФ РИФКАТЬ УЛЫ ҖАМАЛЕТДИНОВ БЕЛӘН СӨЙЛӘШТЕК.

**- Рәдиф Рифкатович, 2012 ел Филология һәм сәнгать институты өчен ни дәрәҗәдә уңышлы булды?**

Гайре табигый күренештер инде ул, һәркайсыбыз да ел тәмамланганда, тагын бер кат артка таба күз салып, үткәндәге вакыйгаларны, үзебез белән бәйле хәлләрне барлап, аларга нәтиҗә ясый. Әмма шунысы хак: һәр вакыйга да бу тормышта эзсез калмый. Уңайлары безнең эштә үрнәк булып тора, алар алга таба да хәрәкәт итәргә мөмкинлек бирә, ә инде үкенечлеләре, әлбәттә, гыйбрәт. Фәнни һәм белем бирү мәсьәләләрен көндәлек гыйбарәләр һәм гади үрнәкләр белән генә аңлатып бетереп булмый. Шуны гына билгеләп үтү дә җитә: моңа кадәр дә яхшы җиһазландырылган институтыбыз КФУның үсеш программасы кысаларында яңа музыка кораллары, компьютер һәм лингафон җиһазлары белән тулыландырылды. Бүгенге көндә студентларыбыз 12 лингафон кабинетында инглиз, француз, немец, испан телләре белән беррәттән, рус һәм татар телләрен дә өйрәнәләр. Бу, һичшиксез, без әзерли торган белгечләрнең сыйфатында уңай чагылыш табачак.

**- 2012 елда кабул ителгән студентлар турында ни әйтерсез?**



**- Уку йорт**ына кабул итү кампаниясе нәтиҗәләре барыбызны да сөендерә. Мәгълүм ки, демографик хәлгә бәйле рәвештә мәктәпләрдә укучылар саны елдан-ел кими бара. Шуңа бәйле рәвештә абитуриентлар да азая. Әмма КФУның Филология һәм сәнгать институты 2012-2013 уку елына кабул итү буенча фаразланган күрсәткечләрне арттырып үтәде. Безгә укырга керүчеләрнең белем дәрәҗәсенә килгәндә, Бердәм дәүләт имтиханнары буенча уртача балл 71,8не тәшкил итте. Бу - чагыштырмача югары күрсәткеч. Әлбәттә, абитуриентлар арасында уртача 85-90 балл җыючылар да булды. Димәк, безгә укырга керүчеләрнең мәктәпләрдә алган белем дәрәҗәсе түбән түгел. Инде менә 1 семестр тәмамланды һәм без бүгенге көндә шундый баллар белән кабул ителгәннәрнең беренче яртыеллыкны ничек тәмамлауларын тикшереп, нәтиҗәләр чыгарырга җыенабыз. Шушы көннәрдә укуда иң алдынгыларның әти-әниләренә Рәхмәт хатлары җибәрелде.

**- Узган ел нинди вакыйга белән исегездә калыр икән?**

- Әлбәттә, вакыйгалар шактый һәм аларның һәркайсы үзенчәлекле һәм әһәмиятле. Быел республикада беренче тапкыр татар теле һәм әдәбиятыннан Халыкара олимпиада оештырылды һәм анда безнең институт төп оештыручыларның берсе булды. Ул ике турда үткәрелде. Чарага дөньяның төрле почмакларында – Финляндия, Төркия, Әзербайҗан, Үзбәкстан һәм Россиянең төрле төбәкләрендә яшәүчеләр килде. Бүген урыс-татар, татар-урыс тәрҗемәчеләренә ихтыяҗ бар. Мәгариф учреждениеләре белән эшләү барышында моның өчен әзерлекле абитуриентлар туплау, балаларны бу юнәлешкә җәлеп итү фикере туды. Нәкъ шул максаттан чыгып, «Татарларга тылмач кирәк» дигән конкурс оештырдык. Әлеге конкурста 9-11 сыйныф укучылары катнашты. Болар, нигездә, Татарстан балалары. Бүген без Россиянең башка төбәкләреннән дә тәкъдимнәр алабыз.

**- Сез җитәкли торган институт республика күләмендә дә бик күп проектларны тормышка ашыра.**

- КФУның 2010-2019 елларга үсеш программасын гамәлгә ашыру максатыннан, ФСИ галимнәре тарафыннан фәнни-тикшеренү эшчәнлегенә тышкы инвестицияләр җәлеп итү буенча саллы эшләр башкарылды. Әйтик, максатчан федераль программа кысаларында, төрле типтагы белем бирү оешмаларының рус теле өлкәсендә хезмәт итүче мөгаллимнәре һәм белгечләренең квалификациясен күтәрү проекты уңышлы гамәлгә ашырыла башлады. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов тәкъдиме белән гамәлгә ашырылучы «Ана теле» проектында да безнең институт мөгаллимнәре актив катнаша. Татарстан Министрлар Кабинеты ярдәме белән безнең уку йорты оештырган татар теле курслары иң күп кеше кызыксынган чараларның берсе булды. Ике этаптан торган әлеге курсларда 1 меңләп милләт вәкилләре, һөнәр ияләре татар телен өйрәнде. Бу чараны да институтның олуг бер казанышы дип саныйм.

**- Филология һәм сәнгать институты бөтенроссия дәрәҗәсендәге чаралар, Халыкара форумнарны күпләп уздыруы белән дә дан тота.**

- Бүгенге көндә кешеләрнең үзләре өчен яңа кыйммәтләр ачуы, башка халыкларның мәдәниятләре аша гомумкешелек кыйммәтләренә якынаюы, шәхесара һәм мәдәниятара аралашуга өйрәнүе аеруча мөһим. Боларны хәл итү өчен, җәмгыятьтә телләр өйрәнүнең әһәмиятен үстерү һәм киләчәк буыннарда үз халкына, мәдәниятенә хөрмәт тәрбияләү зарур. Әлеге көнүзәк мәсьәләләр турында фикер алышу, туган телләр һәм мәдәниятләрне үстерү, шулай ук бу юнәлештә алдынгы тәҗрибәне гомумиләштерү ихтыяҗын истә тотып, Казан (Идел буе) федераль университетының Филология һәм сәнгать институты «Туган телләрне һәм әдәбиятларны саклау һәм үстерү» халыкара фәнни-гамәли форумын уздырды. Аның кысаларында бик күп чаралар оештырылды. Студентлар арасында массакүләм мәдәни һәм спорт чаралары да зур оешканлык белән уза һәм аларда безнең студентлар һәрвакыт актив катнашып, танылып киләләр. «Начни с нами!», «Метро», «Сәламәтлек поезды», «Фиеста», «Беренче курслар» көне, «Студентлар язы» кебек чаралар инде матур бер традициягә әйләнде.

Студентларның иҗади осталыкларын үстерү максатыннан оештырылган «Илһам» һәм «Әллүки» әдәби-иҗат берләшмәләренә йөреп, каләм чарлаган студентларыбыз республикакүләм иҗади бәйгеләрдә һәрвакыт танылып киләләр. Алай гына да түгел, шушы берләшмәләрнең иң актив иҗатчылары инде бүген яшь язучылар һәм шагыйрьләр. «Мизгел» халык театры исә быел драматург Туфан Миңнуллин исәлегенә аның «Саташу» спектаклен сәхнәләштерде. Халык иҗатының «Милли хәзинә» Идел буе яшьләр конкурс-фестивале дә өченче тапкыр уздырылып, анда Татарстан һәм Россиянең берничә төбәге яшь һәвәскәрләре үзләренең иҗады осталыкларын күрсәтте.

**- Яңа 2013 елны нинди планнар, максатлар белән каршы алдыгыз?**

- 2013 елга ният-максатларыбыз зурдан. Студентларга һәр белгечлек буенча белем бирүдә иң заманча алымнарны киң кулланып, укуның сыйфатын тагын да яхшырту. Барлык өлкәләрдә әлегә хәтле безнең элеккеге кафедраларыбыз һәм бүлекләребездә уздырылып килгән фәнни, тәрбияви һәм мәгариф өлкәсендәге зур чараларны үткәрүне дәвам итәчәкбез. Алдагы уку елыннан яңа юнәлешләр һәм белгечлекләр дә ачарга ниятлибез. Болар турында без февраль аенда тулырак мәгълүмат бирербез.

## Илшат Гафуров: «Хезмәт хаклары артачак»!

**Башы 1нче биттә.**


Ял итү урыннарын да тернәкләндерәбез. Кайдадыр яңалары төзелә, кайдадыр ремонт бара. Территорияләребез зурайды, шуның белән бергә, мөмкинлекләребез дә арта. Соңгы ике ел эчендә бик күп уку кампуслары модернизацияләнде. Сүз дә юк, беренче чиратта фәнни өлкәгә игътибар бирәбез», – диде ректор. Шулай ук уку йортындагы уртача хезмәт хакы турында да мәгълүмат җиткерде. Аның сүзләренчә, хезмәт хакы арту көтелә, ләкин бар кешенекен дә берьюлы күтәреп бетереп булмый. Әйтик, ассистентлар ректор карары нигезендә, хезмәт хакына өстәп, биш мең сум ала. «Профсоюзның яңа составыннан теләк-тәкъдимнәр көтеп калабыз, бигрәк тә социаль инфраструктура буенча. Ләкин алар тормышка ашырырлык булсын иде. Без эшләр өчен шартлар тудырабыз, алардан дөрес итеп файдалану – сезнең эш», – диде һәм яңа җитәкчегә уңышлар теләде.

• Чара

## Татьяна көненең икенче мәгънәсе

**Рифат СӘЛАХ**

23 ГЫЙНВАР КӨННЕ ФИЛОЛОГИЯ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫНЫҢ РУС ФИЛОЛОГИЯСЕ БҮЛЕГЕ АКТЛАР ЗАЛЫНДА УНЫНЧЫ «ТАТЬЯНА КӨНЕ – XXI ГАСЫРДА ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ ҺӘМ ЭСТЕТИКА» КОНФЕРЕНЦИЯСЕНЕҢ АЧЫЛЫШЫ УЗДЫ.



Әмир Фазлыйәхмәтов фотосы

Җыенның исеменнән күренгәнчә, 25 гыйнвар Студентлар көненә туры килү сәбәпле дип уйларга була. Бу фикер дә дөрес, әмма асылда чара Казан дәүләт педагогика университеты доценты Татьяна Геллер исәлегенә оештырыла. Ел саен уздырыла торган белем бәйрәме быел беренче тапкыр Бөтенроссия күләмендә үткәрелә.

Чараны ТР Мәгариф һәм фән министры урынбасары Андрей Поминов, Филология һәм сәнгать институты директоры урынбасары Искәндәр Ярмәкиев ачып җибәрде. Алар бу конференциягә зур өметләр баглады. Монда катнашкан һәр укучы да киләчәктә КФУ студенты булу бәхетенә ирешер дигән уйда калды.

Өч көн барачак әлеге конференция тугыз секциядән тора. КФУның Филология һәм сәнгать институты матбугат үзәге җитәкчесе Сөләйман Нәҗмиев сүзләренчә, быелгы конференциядә беренче мәртәбә мәктәп укучылары катнаша. Бу киләчәктә дә абитуриентларны җәлеп итү, булачак студентларның бүгеннән үк белемен күтәрү өчен эшләнә. Барлыгы 106 укучы алты секциягә бүленеп шөгыльләнәчәк, ә 120 студент һәм магистрантлар өчен өч секция эшли.

Бөтенроссия конференциясендә катнашучылар географиясе дә киң. Чарада Мәскәү, Барнаул, Чабаксар шәһәрләреннән һәм Татарстанның бөтен районнарыннан диярлек вуз укытучылары һәм аспирантлары, студентлар һәм мәктәп укучылары катнаша.

• Бездә кунак бар

## Төркиягә якынаябыз

**Башы 1нче биттә.**

ФСИда төрек теле һәм инглиз теле бүлеге ачылу - ике як өчен дә әһәмиятле адым. Консул хәзерге вакытта студентлар белем ала торган бинага кереп чыгарга күптәннән кызыгып йөргән икән. Ниһаять, теләге тормышка ашкан. Шул уңайдан кунагыбызны институтның тарихы, эшчәнлеге белән дә таныштырып үттеләр.

Алга таба исә киңәшмәдә ике як арасында хезмәткәрләр, студентлар алышуның җиңелрәк юлларын эзләү мәсьәләләре дә каралды. Бу уңайдан Сабри Тунч Ангылы һәрьяклап ярдәм итәргә һәм тәкъдимнәрен җиткереп торырга сүз бирде.

Очрашуның икенче өлешендә консул Төркиядән килгән студентлар белән ачык әңгәмә оештырды. Студентларны кызыксындырган сорауларга җаваплар биреп, һәр мәсьәләгә ачыклып кертеп барды. Яшьләр исә рус студентларының Төркия мәдәнияте, тарихы, шәһәрләре белән таныш булмавына борчыла. Бу уңайдан, Төркиядән килгән студентлар КФУда берәр төрек бүлмәсе ачу мәсьәләсен күтәрде. Филология һәм сәнгать институты директоры Рәдиф Җамалетдинов уку йортыбызда Төркия атналыгы үткәрү фикерен җиткерде.

Очрашудан соң төрек студентлары белән дә гапләшеп алдык. Сүмәя Маниса шәһәреннән, Әминә Караман Манаш шәһәреннән килгән. «Без Россиядә укуыбызга бик шат. Рус һәм инглиз телләрен өйрәнәбез.Чынлап та, монда белемнең сыйфаты яхшы. Татарча гына аңламыйбыз шул. Бердәнбер авырлык рус телен өйрәнү. Бу кыенлыкны уңышлы гына җиңеп чыгарбыз дип ышанабыз», – ди алар.

Огузхан, Балыкесир шәһәреннән, рус-инглиз бүлеге, 1 курс: «Татарстан бик ошый. Бердәнбер проблема: суык сездә. Ныклап торып гыйлем алу һәм Төркиядән килгән студентлар күп булу сәбәпле, сагынырга өлгермибез. Рус телен өйрәнеп бетермәдек әле, ә менә татар дусларым белән аңлашабыз».

● Универсиада

# Ә син волонтер булырга әзерме?

**Зилә ФӘСХИЕВА,**
хәбәрче

Әгәр дә син студент һәм быел Казанда үтәчәк җәйге универсиадага аз булса да үз өлешеңне кертәсең килә икән, бу мәгълүматлар синең өчен кызыклы булачак! 21 гыйнвар көнне Казан федераль университетында 28 нче Бөтендөнья җәйге Универсиадасы өчен рекрутинг, ягъни волонтер булырга теләүчеләрне кабул итү үзәге ачылды.


Алия Галимуллина фотосы

Иң элек «рекрутинг» терминына кыскача билгеләмә биреп үтик. Рекрутинг ул – өстәмә буш урыннарга кадрлар эзләү өчен уңайлы шартлар тудырылган үзәк. Безнең очракта исә ул – волонтерлар туплау үзәге.

Тантананы КФУ ректоры Илшат Гафуров ачып җибәрде. «Без сезнең белән бик бәхетле кешеләр, чөнки илебездә 40 елга бер мәртәбә була торган дөньякүләм спорт ярышы – Универсиаданы күрү бәхетенә ирешәчәкбез», – дигән сүзләр белән ректор килгән кунакларны һәм студентларны волонтерлар үзәге ачылу тантанасы белән тәбрикләде. Бу объектның Универсиада беткәннән соң, яшьләр үзәге булып калачагы да студентларда зур кызыксыну уяткандыр, мөгаен. Рекрутинг үзәге сайлап алган волонтерларның ничек эшләвенә, аралашуына карап, башка ил спортчыларында безнең республикабыз, илебез турында тәэсирләр калачак. Аппарат җитәкчесе Лариса Сулима сүзләренә караганда, Россиянең барлыгы 53 университетында волонтер командалары әзерләнә. Шуңа карамастан, башкарылачак иң мөһим эшләр безнең вуз студентлары өстендә булачак, чөнки 20000 волонтерның 5000е нәкъ менә КФУ студентларына туры килә. Волонтерлар эшләячәк объектлар исәбенә университет авылы, төрле спорт объектлары, күңел ачу, ял итү урыннары керә.

Рекрутинг үзәге 4 өлешкә бүленгән: каршы алу, көтеп тору, интервью, call-үзәк. Эшне барлыгы сигез кеше башкару бер көнгә 100 волонтерны кабул итәргә мөмкинлек бирәчәк. Әңгәмәләр инде үзәкнең ачылу тантанасы булган көнне үк башланды. Иң кызыгы шул: рекрутинг үзәкнең иң беренче символик волонтеры КФУ ректоры Илшат Гафуров үзе булды.

Филология һәм сәнгать институты директоры Рәдиф Җамалетдинов сүзләренчә, университетыбызда шундый үзәкләрнең ачылуы һәм алга таба эшләве барыбыз өчен дә күңелле факт: «Мондый чаралар республика күләмендә гел булып торачак. Һичшиксез, студентларыбыз анда иң алдынгылардан булыр. Ә үзәкнең ачылуы әһәмиятле роль уйнаячак», – дип үзенең фикерләре белән уртаклашты.

Студентларыбыз да бу рекрутинг үзәгенә зур өметләр баглый. Фәлсәфә факультетында 3 нче курста белем алучы Виктория Шарычева волонтер булып эшләячәге белән чиксез бәхетле булуын белдерде: «Минем өчен студент елларында ук мондый төрдәге илкүләм чараларда катнашу - бик зур бәхет. Волонтер булу өчен активлык, үҗәтлек, кешеләр белән аралаша белү һәм бик зур җаваплылыкка ия булырга кирәк. Казандагы универсиаданы уңышлы башкарып җибәргәннән соң, мин әле туктап калырга җыенмыйм. Алдагы максатларым: 2014 елда Сочида узачак кышкы Олимпия уеннарына, аннан соң 2016 елда Рио-де-Жанейрода үткәреләчәк җәйге олимпия уеннарына бару. Шуңа күрә бүген ныклап үз өстемдә эшлим».

Дөрестән дә, ник әле үзеңне сынап карамаска ди? Яңа дуслар табу, танылган кешеләр белән аралашу, җәмгыятькә файдалы булу һәм Универсиаданы үз күзләрең белән күрү безнең студентлар өчен һич кенә дә чыңга ашмас хыял түгел! Бары тик яңа ачылган рекрутинг үзәгенә барып, үзеңне волонтер буларак сынап карарга теләвеңне әйтергә генә кирәк!

● Алхәбәр

# Ел студенты-2012

25 гыйнвар көнне Пирамидада Республикакүләм «Ел студенты» конкурсының нәтиҗәләре игълан ителәчәк. Кемнәр өчен җан атарга соң, диярсез. Менә алар - бәйгенең финал өлешенә чыккан КФУ студентлары һәм алар катнашкан номинацияләр:

**Альбина Галиева,** Елның иң яхшы җәмәгать эшлеклесе,
**Гадел Җәләев,** Елның иң яхшы студентлар хезмәт отряды,
**Ксения Кадочникова,** Ел журналисты,
**Тимур Дәүләтшин,** Ел журналисты,
**Динара Вәлиева,** Ел журналисты,
**Булат Гәрәев,** Юридик факультетның студентлар фәнни җәмгыяте (СНО), елның иң яхшы СНОсы
**Денис Когогин,** Ел интеллекты,
**Роберт Зиннәтуллин,** Ел студенты,
**Энгель Сәйфетдинов,** Ел студенты,
**«Дарелфөнүн» газетасы,** Елның иң яхшы массакүләм мәгълүмат чарасы.

Университетыбыз егет-кызларына һәм үзебезнең «Дарелфөнүн»ебезгә уңышлар телик! Ә кемнәр җиңүче булганын киләсе санда укыгыз!

● Хезмәттәшлек


■ Люксорда очрашу күренеше. Автор фотосы

# Мисыр безгә бик якын!

**Эмма ГАЛИМОВА,**
«Әл-Хадара» Гарәп мәдәнияте үзәге директоры урынбасары

КФУ студентлары хәзерге вакытта Мисырның Люксор шәһәрендә кышкы стажировка үтә. 19 декабрь көнне КФУның «Әл-Хадара» Гарәп мәдәнияте үзәге директоры Мөхәммәд Салих Әл-Әммари Люксор шәһәре мэры Гыйззәт Сәгъд белән рәсми очрашу үткәрде.

Очрашуда «Әл-Хадара» Гарәп мәдәнияте үзәге белән Люксор шәһәре хакимияте үзара хезмәттәшлек мәсьәләләрен хәл итте. Сөйләшү барышында Татарстанда март аеның икенче яртысында Мисырга багышланган гарәп мәдәнияте көннәре үткәрү турында килешенде. Шул көннәрдә Татарстан башкаласы Казан белән Мисырның Люксор шәһәрләре арасында туганлашлык килешүе имзаланыр дип көтелә.

Бу очрашуда Мисыр тышкы эшләр министрлыгының БДБ илләре белән фәнни хезмәттәшлек буенча Мисыр фондының тел стажировкасы координаторы Халид Шәрәф, мәгълүмати киңәшче Әхмәд Нуби, Люксор мэриясенең чит ил репортерлары үзәге директоры Али Бәдәви, Мисыр Туризм һәм планлаштыру министрлыгының беренче вәкиле Габделхәмид Яхъя да катнашты.

Люксор шәһәре башлыгы Гыйззәт Сәгъд «Әл-Хадара» гарәп мәдәнияте үзәгенә ике дустанә ил халкын тагын да якынайткан өчен рәхмәтен белдерде, Татарстан студентлары делегациясенә истәлекле бүләкләр тапшырды.

● Дөнья үзебезнеке

# Студент һәм студентлык турында берничә факт

✓ Күпчелек япон студентлары имтиханга үзләре белән шоколад алып керә. Аның да теләсә-нинди түгел, ә безгә яхшы таныш булган «Kit Kat»ны. Әлеге шоколад алар өчен талисман икән. Бу шоколадның исеме япон телендәге «kitto katsu» «һичшиксез җиңәчәкбез» сүзтезмәсе белән авазлаш булудан килә.

✓ Беркем өчен дә яңалык түгел: һәрбер университетта да лекция вакытында йокыга китүче студентлар җитәрлек. Франциядә бу мәсьәләне бик үзенчәлекле хәл итәргә тырышканнар. Нант шәһәрендәге университетта студентларга ял итү өчен махсус бүлмә оештырганнар. Һәр студент теләгән вакытында анда кереп чын мәгънәсендә дөнья мәшәкатьләреннән арынып утырырга мөмкин. Бу бинада тәмәке тартырга, кычкырып сөйләшергә, музыка тыңларга, кочаклашырга һәм үбешергә катгый рәвештә тыела.

✓ Танылган Йельс университетында озак еллар буе сакланып килә торган сәер традиция бар. Югары курслар үзләренең конспектларын беренче курс студентларына бирә. Моның өчен беренчеләр аларга тиеш булып кала. Бу очракта матди як күздә тотылмый. «Бурычлы» кешенең күзләрен зеленка белән йөртәләр, алар фараларга охшап калырга тиеш. Шуннан соң беренче курслар өлкәннәрне тәүлек буе яисә берничә сәгать аркаларында күтәреп йөрергә тиеш була.

✓ Моннан 200 ел элек, XIX гасырда, Россиядә ресторан, кабак һәм эчемлекләр сатыла торган башка биналарда студентларның аркаларына адресларын язып куя торган булганнар. Аннан соң извозчиклар исереп беткән укучыларны адреслары буенча өйләренә кайтарып куйган.

✓ Күп кенә чит ил университетларында бүгенге көндә дә кулланыла торган тагын бер сәер традиция бар. Аны «борынгылар тавышы» дип йөртәләр (ингл. «The Primal Scream»). Студентларның мондый тавышы Тарзан һәм футбол җанатарларының кычкырулары белән охшаш. Гадәттә ул 5-10 минут дәвам итә. Сессия вакытында студентларга университет территориясендә мондый тавыш чыгару рөхсәт ителә. Ул борчылганлыктан котылырга ярдәм итә, имеш.

✓ АКШтагы Принстон университетында студентларның язма имтиханнары вакытында аудиториядә укытучы булмый. Бу университет кабул иткән «Намус кодексы» белән аңлатыла. Бу традицион сүз бирү тантанасында барлык беренче курслар да катнашырга тиеш. Ант биргәндә алар тәртибе югары дәрәҗәдә булган гражданнар буларак, имтиханда күчермәскә дә вәгъдә бирә.

✓ АКШның Джорджтаун университеты да кызык һәм көлкеле традицияләрдән читтә калырга тырышмый. Университет студентлары Healy Hall манарасы сәгатенең укларын борып алып урлыйлар һәм, никтер, аны махсус посылка белән Ватиканга Рим Папасына җибәрәләр. Университет администрациясе таләпләре һәм җирле сакчылар тырышлыгына карамастан, сәгать уклары даими рәвештә 5-6 елга бер тапкыр юкка чыга.

● Читтә дә безнекеләр

# «Гади студентлар массасыннан аерылмыйбыз!»

**Алинә САДЫЙКОВА,**
хәбәрче

Әлеге фотолардагы егет белән кызны бер дә охшаган дип булмый. Екатерина Малярова Казахстаннан килгән һәм ул I курста белем ала. Солтан Тохтомбаев исә Кыргызстанда туып үскән, бүгенге көндә III курста укый. Шулай да аларны берләштерә тора торган әйбер бар: алар икесе дә – Казан федераль университетының юридик факультетында укучы чит ил студентлары!





**– Нигә уку йорты итеп нәкъ менә Казан федераль университетын сайладыгыз?**

***Е.М.:*** Юридик факультетта уку – ул күптәнге хыялым. Минем шәһәргә квота килде һәм Казанда юридик факультетта урыннар булгач, мин бершиксез ризалаштым. Беренчедән, КФУ – Россиянең иң борынгы уку йортларының берсе. Минем, һичшиксез, мондый белем сараенда укыйсым килгән иде. Икенчедән, Универсиада авылы булу да йогынты ясады. Анда тудырылган мөмкинлекләрне әйтеп бетерә торган түгел. Башка университет тулай торалары белән чагыштырганда, бу җәннәт рәхәтлекләре белән бер. Өченчедән, мин Казахстанда туып үстем, Казандагы мөселман мохите минем күңелгә ятышлы булыр дип уйладым. Мондый тирәлектә үземне туган якларымда шикелле хис итәрмен сыман тоелды. Бар да мин уйлаганча булды. Бу адымны ясаганыма һич тә үкенмим.

***С.Т.:*** Бездә Казан университеты күптәннән бик югары бәяләнә. Мәктәпне бетергәндә үк, монда укырга киләсемне белә идем. Шуңа күрә минем өчен башка вариантлар булырга мөмкин дә түгел иде. Әтиәнием дә фикерем белән килеште. Аннары Казан – бик матур һәм борынгы шәһәр. Мине бигрәк тә биналарның архитектурасы җәлеп итә. Беренче чиратта, әлбәттә, ул – КФУның колонналы төп бинасы. Кремль дә бик ошый. Беренче курста укыганда, дусларым белән көн саен диярлек шул тирәләрне әйләнеп кайта идек. Хәзер, кыш көне, алай йөрергә бераз кыенрак. Монда өченче елымны яшәсәм дә, Россиянең кырыс кышларына иялəнеп бетеп булмый.

**– Казан университеты сезнең өметләрегезне акладымы?**

***Е.М.:*** Әйе, чөнки 200 елдан артык тарихы булган, югары үрләр яулый алырлык шәхесләр тәрбияләгән шушы колонналы бина эчендә булганда, мин дә үземне шуларның бер өлеше кебек тоям. Шул ук вакытта әлеге уку йорты синә тормышта үз урыныңны табарга, чын мәгънәсендә шәхес булып өлгерергә барлык мөмкинлекләрне дә тудыра. Укуга килгәндә, мин моның кадәр авыр булыр дип уйламаган идем. Кайбер чакларда 100, хәтта 200 процентка бирелергә, төннәрен йокламаска, барлык көчне түгәргә туры килә. Ничек кенә кыен булмасын, миңа бу бик ошый. Минемчә, нормаль студент шулай булырга тиеш тә: уку – уку инде ул!

***С.Т.:*** Әйе, мин зарланмыйм, барысы да ошый. Мөнәсәбәт тә бик яхшы. Чит ил студенты дип аермыйлар бездә: килгәнсең икән укы! Башка студентлар белән бертигез куеп, искәрмәләр ясамыйча укытулары, минемчә, бик дөрес. Без гади студентлар массасыннан аерылмыйбыз. Уку программасы бик тыгыз һәм авыр булуга карамастан, мин белем алуга күп көчемне сарыф итәм, ансыз булмый да. Кыенлыкларга килгәндә, кайчакта кешеләр русча бик кызу сөйләшкәндә, кайбер сүзләрне отып алу җайсызрак.

**– Башка уку йортларында укучы чит ил студентлары белән элемтәдә торасызмы?**

***Е.М.:*** Шәһәрара конференцияләр булган вакытта, башка уку йорты студентлары белән очрашабыз, аралашабыз. Шулай да, күпчелек КФУдагы чит ил студентлары белән хәбәрләшеп торабыз.

***С.Т.:*** Әлбәттә, гел дә аралашып торабыз. Мисал өчен, КГТУда укый торган танышларым бар. Алар белән сөйләшеп утырганда, уку турында да фикер алышмый калмыйбыз. Аларның уку программалары безнеке белән чагыштырганда җиңелрәк, кайчакта алардан көнләшеп тә куям. Әмма тулай торак мәсьәләсенә килгәндә, бездә булган шартлар аларның төшләренә дә кермими!

**– Сезгә, чит ил студенты буларак, барлык шартлар да тудырылганмы?**

***Е.М.:*** Безне монда килгәнче: «документларыгызны йөзегезгә кире ыргытырга мөмкиннәр, анда сезне берәү дә көтми», дип әйткәннәр иде. Чынлыкта исә, Тышкы элемтәләр департаментында безне бик җылы каршы алдылар: документлар мәсьәләсен тиз арада хәл итеп, тулай торакка урнаштырдылар. Шартларга килгәндә, чит ил студентларын кайчагында җирле белем алучыларга караганда күбрәк тә кайгырталар. Барлык мөмкин булган шартлар да тудырылган: без шул ук стипендия, ташламалар алабыз. Миңа бигрәк тә КФУда Тышкы элемтәләр департаменты, Чит ил студентлары советы булу бик ошый. Без, факультет студсоветы белән беррәттән, анда да үз-үзебезне күрсәтә алабыз. Алар икесе ике структура һәм икесендә дә мөмкинлекләр бик күп.

***С.Т.***: Шартлар, әлбәттә, тудырылган. Укырга теләге булган кешегә барлык мөмкинлекләр дә бар. Уку авыр дияргә яратабыз. Шуңа да җиңел генә бирелә торган әйбер түгел ул. Универсиада авылында тору бик ошый. Шунсы гына бераз кыен: тулай торактан уку йортына кадәр барып җитү күп вакытыбызны һәм көчебезне ала.

**– Укуны тәмамлаганнан соң, Казанда калырга уйлыйсызмы?**

***Е.М.:*** Кире Казахстанга кайтырга җыенмыйм. 15 яшьлек вакытымда Россиягә китәчәгемне белә идем. Казанда калырмынмы, әллә бүтән җиргә китәрменме, әлегә төгәл генә әйтә алмыйм. Ник дигәндә, әле укыйсы күп, магистратурага керергә дә теләгем бар.

***С.Т.:*** Казанда кала алмыйм, чөнки, килешү буенча, кулга диплом алганнан соң, безгә кире туган ягыбызга кайтып китәргә туры киләчәк. Әгәр мөмкинлек булса да, калмас идем дип уйлыйм. Монда ничек кенә рәхәт булмасын, барыбер туган як, якын кешеләр сагындыра.

**– Укудан кала ниләр белән шөгыльләнәсез?**

***Е.М.:*** Бик күп әйберләр белән шөгыльләнәсем килә, әмма уку шактый вакытымны ала. Шулай да, мөмкинлек булганда, дусларым белән аралашырга тырышам. Универсиада авылында безгә, чит ил студентларына, аерым өй бүлеп бирелгән. Без бик еш төрле бәйрәмнәр, концертлар оештырабыз. Мин үземнең мондый «эшчәнлегемне» беренче курсларның багышлау кичәсеннән башлап җибәрдем. Чиратта – Халыклар дуслыгы фестивале. Менә күптән түгел генә, декабрь аенда, Католик Раштуасын уздырдык. Европа студентлары үткәрде, без оештыру эшләре белән ярдәм иттек. Алга таба да бәйрәмнәр җитәрлек: 14 февраль, 23 февраль, 8 март, Нәүрүз. Аларны да үткәрергә җыенабыз. Спорт турында да онытмыйм: баскетбол белән шөгыльләнәм. Бәлки берәр кайчан университет командасына да эләгермен әле.

***С.Т.***: Мин спорт белән шөгыльләнергә, төгәлрәге, футбол уйнарга яратам. Сүз уңаеннан, хәзер Казандагы чит ил студентлары арасында футбол лигасы башланып китте. Минем белән бергә Кыргызстаннан килгән, бергә укыган иптәшем – Данияр Иманалиев – безнең команданың менеджеры. Ул команданы җыйды, туплады, көрәшкә әзерләде. Мин исә команданың капитаны. Тиздән ярышлар башланачак, без бу вакыйганы зарыгып көтәбез. Студентлар лигасы исә спонсорыбыз. Алар безне форма, спортзаллар белән тәэмин итеп торалар. Аларга бик зур рәхмәт. Чит ил советы уздырган вакыйгалардан да читтә калырга тырышмыйбыз. Һәммәсендә катнашып бармасак та, аларны оештыруга өлешебезне кертәбез.

**– Татьяна яки студентлар көнен ничек үткәрергә җыенасыз?**

***Е.М.***: Быел ул – минем дә бәйрәм! Минем өчен бу беренче тапкыр, шуңа күрә аннан ни көтәсен белмим. Шулай да, бу көнне үзенчәлекле, истә калырлык итеп үткәрәсем килә.

***С.Т.:*** Безнең Кыргызстанда студентлар көне уку елы башында үткәрелә. Монда башкача икән. Үзем студент булсам да, бу бәйрәмне бик әһәмиятле дип санамыйм. Сүз дә юк, бу уңайдан оештырылган чараларда катнашам. Мисал өчен, беренче курста булганда, УНИКСта узган концертта безне чит ил студентлары буларак, сәхнәгә чакырып, бер-ике сүз әйттергәннәр иде. Шулай да, мин аңа аерым зур бәйрәм итеп карамыйм.

● Сораштыру

# Безнең дә һөнәри бәйрәм бар!

**Алинә САДЫЙКОВА,**
**Динара МИННЕКАЕВА,**
хәбәрчеләр

Сессия, имтиханнар тәмамланганнан соң, студентларыбызга күп ял итәргә насыйп булмады. Моңа көн саен сөйләнә торган Универсиада сәбәпче. Шулай да, вакыйгалар мондый борылыш алуының уңай ягы да бар: студентларыбызга үзләренең «һөнәри» бәйрәмнәрен оештыру һәм югары дәрәҗәдә уздыру өчен, менә дигән мөмкинлек. Әйе, тиздән Татьяна көне, ягъни студентлар көне! Безнең студентларыбыз бу бәйрәмгә ничек карый икән?



***Айсылу Ханнанова,*** *Икътисад һәм финанс институты, III курс:*

Студент буларак, мин бу вакыйгага һөнәри бәйрәм буларак карыйм. Ул - бөтен студентларны бергә бәйли торган көн. Безнең КФУда әлеге бәйрәм аеруча истә калырлык итеп үткәрелә: ректор һәм администрация котлаулары, концерт. Үземне һәм коллегаларымны бәйрәм белән котлыйм! Алган белемнәребез нигезле һәм тормышта кирәкле булсыннар иде. Студент еллары һәрберебезнең күңелендә дуслык, иҗади уңышлар, белән тулы бәхетле чор булып калсын иде.



**Роза Сәхбетдинова,** *КФУның Алабуга институты, V курс:*

Бу көнне мин дуслар, танышлар, туганнардан котлаулар кабул итәм. Студентларны үзем дә котлыйм. Студент булып йөргән шушы биш елда әлеге исемне йөрткәнем өчен горурланам да, сөенәм дә. Ә быелгы Татьяна көне иртәгә имтихан буласы көнгә туры килә. Бу исә бәйрәм имтиханга әзерләнеп үтәчәк дигән сүз! Студент буларак, быел мин ул көнне соңгы тапкыр каршылыйм. Һичшиксез, студент елларын, университетыбызны, укытучыларыбызны, бу бәйрәмне сагыначакмын!



**Гөлшат Галәвиева,** *Фундаменталь медицина һәм биология институты, IV курс*:

Бу бәйрәмне студентлар аеруча көтеп ала. Студентларга бу көнне мактау кәгазьләрен тапшыру бик дөрес дип саныйм. Күпчелек студентлар шикелле үк, мин дә дусларым белән бергә җыелып, дискотекага барырга җыенам. Анда күңел ачып, имтиханнарны әйбәт кенә тапшыруны бәйрәм итәрбез.



**Гүзәл Миннекаева,** *Экология һәм география институты, III курс:*

Бу бәйрәм иң күңелле вакыйгаларның берсе: имтиханнар бирелгән, студентлар ял итә. Быел шәһәребездә Универсиада уздырылу уңаеннан, имтиханнар иртәрәк тапшырылды, каникуллар да кыскартылды. Шуңа да карамастан, университетыбызда студентлар көнен билгеләп узарлар дип уйлыйм.



**Равилә Әхмәтова,** Идарә итү һәм территориаль үсеш институты, IV курс: Студентлар көнен әллә ни зур бәйрәм буларак кабул итмәсәм дә, ул көнне кәеф аеруча күтәренке, шат була. Дуслар белән котлау сүзләре алышабыз. Аны Татьяна көне буларак үткәрүче татар студентларын, гомумән, аңламыйм. Студентлар көне буларак кабул итсәк иде! Сүз уңаеннан, барлык студентларны бәйрәмебез белән котлап, укуда зур уңышлар, җиңеллек һәм яңа җиңүләр телим!

DARELFØNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Рифат Гали улы Сәлахов
Иҗат коллективы: Д.Р.Миннекаева, А.Ю.Садыйкова, З.Ф.Фәсхиева, Д.Р.Зиннәтова
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.

Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Карти» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Восстание ур., 60 й.